ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.12.2021 ел Баулы шәһәре № 213

Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2011 елның 22 июньдәге «Хезмәт өчен түләү Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Баулы муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында»гы 134 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 30 октябрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 июнендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган хезмәт хакын арттыру турында»гы 477 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 1029 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2011 елның 22 июньдәге «Хезмәт өчен түләү Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Баулы муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында»гы 134 нче карарына (Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2012 елның 10 декабрендәге 281 номерлы, 2013 елның 24 октябрендәге .№ 252 номерлы, 2014 елның 22 гыйнварындагы 18 номерлы, 2014 елның 31 октябрендәге 330 номерлы, 2015 елның 20 декабрендәге 319 номерлы, 2016 елның 8 июлендәге 219 номерлы, 2017 елның 10 августындагы 350 номерлы, 2018 елның 15 гыйнварындагы 11 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

күрсәтелгән карарга 1 нче кушымтаны әлеге карар кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының җитәкчесенең
2011 елның 22 июнендәге
134 номерлы карарына
1 нче кушымта
(Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 6 декабрендәге
213 номерлы карары
редакциясендә)

Баулы муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлар)

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | 1,0000 | 13 617,0 |
| 2 | 1,0178 | 13 860,0 |
| 3 | 1,0362 | 14 110,0 |
| 4 | 1,0538 | 14 350,0 |
| 5 | 1,0736 | 14 620,0 |
| 6 | 1,0927 | 14 880,0 |
| 7 | 1,1133 | 15 160,0 |
| 8 | 1,1331 | 15 430,0 |
| 9 | 1,1530 | 15 700,0 |
| 10 | 1,1743 | 15 990,0 |
| 11 | 1,1948 | 16 270,0 |
| 12 | 1,2168 | 16 570,0 |
| 13 | 1,2389 | 16 870,0 |
| 14 | 1,2609 | 17 170,0 |
| 15 | 1,2837 | 17 480,0 |
| 16 | 1,3072 | 17 800,0 |
| 17 | 1,3307 | 18 120,0 |
| 18 | 1,3549 | 18 450,0 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (окладына) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1 – 2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.

______________________